| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 1 июль № 480

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 25 май, 200 нче карары белән расланган Гражданнар, юридик затлар һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары саклый торган су биология ресурслары төрләрен юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару аркасында китергән зыянны түләттерү күләмен исәпләү өчен таксаларга үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРА БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар, юридик затлар һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары саклый торган су биология ресурслары төрләрен юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару аркасында китергән зыянны түләттерү күләмен исәпләү өчен таксаларны раслау турында» 2007 ел, 25 май, 200 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 июнь, 451 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар, юридик затлар һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары саклый торган су биология ресурслары төрләрен юкка чыгару, законсыз тоту яки чыгару аркасында китергән зыянны түләттерү күләмен исәпләү өчен таксаларга түбәндәге үзгәрешне кертергә:

искәрмәләрнең 4 пунктында «Балыкчылык буенча федераль агентлыкның «Идел-Каспий балык хуҗалыгы бассейны өчен Балыкчылык кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 13 гыйнвар, 1 нче боерыгы белән» сүзләрен Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Идел-Каспий балык хуҗалыгы бассейны өчен Балыкчылык кагыйдәләрен раслау турында» 2014 ел, 18 ноябрь, 453 нче боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\480.doc